РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.03.2020 № 523-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районында гражданнар оборонасын алып
баруга әзерлек һәм алып бару тәртибе
турындагы Нигезләмәне раслау хакында

“Гражданнар оборонасы турында” 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының “Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы, “Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2008 елның 22 ноябрендәге УП-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән, гражданнар оборонасы чараларын һәрьяклап тәэмин итүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче М. Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
24.03.2020
523-п
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм алып бару тәртибе турында нигезләмә**

**1.** Әлеге Нигезләмә “Гражданнар оборонасы турында” 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенец “Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, “Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында” 2008 елның 22 ноябрендәге УП-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы һәм Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының “Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында” 2008 елныц 14 ноябрендәге 687 номерлы приказы белән расланган муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмә нигезендә эшләнгән һәм гражданнар оборонасын алып баруга әзерлекне һәм алып баруны оештыруны һәм аныц төп юнәлешләрен, шулай ук Татарстан Республикасыныц Саба муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча топ чараларны билгели.

**2.** Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракларда саклау чараларын алдан ук үтәүдән гыйбарәт һәм ул Саба муниципаль районыц Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү (алга таба – төп чаралар планы) мәсьәләләре буенча төп чараларны күздә тоткан еллык һәм перспектив планнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

**3.** Бер елга төп чаралар планы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан эшләнә һәм Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының территориаль органы – Татарстан Республикасы буенча гражданнар оборонасы бурычларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бурычларын хәл итү өчен махсус вәкаләтле орган белән килештерелә.

**4.** Муниципаль дәрәҗәдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек муниципаль берәмлектә (оешмада) гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмә белән билгеләнә һәм муниципаль берәмлек территориясендә халыкны (хезмәткәрләрне), матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә килеп

чыккан куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очраклардан саклау чараларын планлаштырудан гыйбарәт.

Гражданнар оборонасын муниципаль дәрәҗәдә алып бару гражданнар оборонасы һәм муниципаль берәмлекләрнең халкын саклау планнары нигезендә, ә оешмаларда аларның гражданнар оборонасы планнары нигезендә гамәлгә ашырыла һәм муниципаль берәмлек территориясендә халыкны (хезмәткәрләрне), матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очраклардан саклау чараларын үтәүдән гыйбарәт.

**5**. Гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау планы (Гражданнар оборонасы планы) Гражданнар оборонасы үткәрү һәм хәрби һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чараларның күләмен, оештырылуын, тәэмин итү тәртибен, ысулларын һәм вакытларын билгели.

Гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чараларны үтәү гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чаралар планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

**6.** Җирле үзидарә органнарында гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү аларның идарә органнары, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы көчләре һәм чаралары белән гамәлгә ашырыла.

Җирле үзидарә органнары гражданнар оборонасы буенча җирле дәрәҗәдәге гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итүче оешмалар исемлеген билгели.

**7.** Саба муниципаль районы Башкарма комитеты, Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында, гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләр нигезендә, гражданнар оборонасы объектлары, көчләре, чараларын, матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыра һәм үз эченә ала, гражданнар оборонасы чараларын планлаштыра һәм тормышка ашыра.

**8.** Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча медицина, инженер, коммуналь-техник, янгынга каршы, җәмәгать тәртибен саклау, хайваннар һәм үсемлекләрне саклау, хәбәр итү һәм элемтә, мәдәни кыйммәтләрне саклау, автотранспорт, сәүдә һәм туклану һ.б. коткару хезмәтләре булдырыла ала, аларның эшчәнлеге тәртибе һәм оештырылуы, аларны булдыручы орган тарафыннан коткару хезмәтләре (Гражданнар оборонасы хезмәтләре) турындагы тиешле нигезләмәләрдә билгеләнә.

Җирле үзидарә органының коткару хезмәте составына гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү, авария-коткару формированиеләренең гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү, хәрби конфликтлар вакытында яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетергәндә башка кичектергесез эшләр башкару өчен билгеләнгән гражданнар оборонасының идарә органнары, көчләре һәм чаралары керә.

Җирле үзидарә органы тарафыннан төзелә торган коткару хезмәтләренец торе һәм саны Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә башкарыла торган бурычларның күләмен һәм характерын исәпләү нигезендә билгеләнә.

Саба муниципаль районының коткару хезмәте турындагы нигезләмә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан эшләнә, Татарстан Республикасының тиешле коткару хезмәте җитәкчесе белән килештерелә һәм Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан расланa.

Саба муниципаль районында һәм оешмаларда көчләр һәм чараларның әзерлеген булдыру һәм тәэмин итү белән методик җитәкчелек итү, шулай ук бу өлкәдә контроль Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла – казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы (алга таба-Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы) һәм Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**9.** Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан эвакуация кабул итү чараларын планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү очен алдан ук эвакуация кабул итү комиссиясе төзелә. Эвакуация кабул итү комиссиясе белән Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе яки Җитәкче урынбасары җитәкчелек итә. Эвакуация кабул итү комиссиясенец эшчәнлеге Саба муниципаль районының гражданнар оборонасы җитәкчесе тарафыннан расланган эвакуация кабул итү комиссиясе турында Нигезләмә белән регламентлана.

**10**. Гражданнар оборонасы көчләре тыныч вакытта табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чараларда катнашу очен җәлеп ителергә мөмкин.

Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү очен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын тыныч вакытта җәлеп итү турындагы карарны җирле үзидарә органының Гражданнар оборонасы җитәкчесе үзе төзегән гражданнар оборонасы көчләренә карата кабул итә.

**11**. Саба мунициципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы белән җитәкчелек итүне Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе башкара.

Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау чараларын оештыру һәм үткәрү очен шәхси җавап тота (1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законныц 11 статьясы).

**12.** Саба муниципаль районында гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыру анық турындагы Нигезләмә нигезендә Саба мунициципаль районы Башкарма комитетына йөкләнгән.

**13.** Гражданнар оборонасы буенча чараларны оешкан һәм планлы рәвештә гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шул исәптән тыныч вакытта һәм сугыш вакытында фаразланучы һәм барлыкка килгән куркынычлар турында халыкка үз вакытында хәбәр итү максатыннан, Саба муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю (алга таба –

мәгълүмат) һәм аның белән алмашу оештырыла.

Мәгълүмат җыю һәм аның белән алмашу җирле үзидарә органнары, шулай ук билгеләнгән тәртиптә I һәм II класслы куркыныч җитештерү объектларын, аеруча радиацион куркыныч һәм атом-төш куркыныч җитештерү һәм объектларны, гадәттән тыш куркыныч булган гидротехник корылмаларны һәм югары куркыныч булган гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүче һәм гражданнар оборонасы категориясенә кертелгән оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Саба муниципаль районы Башкарма комитеты мәгълүматны Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына тапшыра.

**14.** Саба муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы чаралары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының норматив хокукый актлары (Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының “Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында” 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы белән расланган муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмә белән) һәм әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

**15.** Саба муниципаль районы Башкарма комитеты, гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатыннан, түбәндәге төп чараларны планлаштыра һәм тормышка ашыра:

15.1. Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләү буенча түбәндәгеләр:

– Саба муниципаль районының үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган үрнәк программалар нигезендә, эшләүче халыкны, вазыйфаи затларны һәм гражданнар оборонасы хезмәткәрләрен, Саба муниципаль районы формированиеләренең һәм хезмәтләренең шәхси составын әзерләү буенча үрнәк программалар эшләү;

– Саба муниципаль районы халкын хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп туган куркынычлардан саклау ысулларына әзерләү һәм оештыру;

– Саба муниципаль районы формированиеләренең һәм хезмәтләренең шәхси составын әзерләү;

– гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм күнекмәләр үткәрү;

– Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең, шәхси составының һәм хезмәтләренең әзерлеген оештыру-методик җитәкчелек итү һәм тикшерүдә тоту ;

– гражданнар оборонасы курсларын һәм гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктларын булдыру, җиһазлау һәм аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук тиешле лицензиясе булган өстәмә һөнәри белем бирү учреждениеләрендә Саба муниципаль районы гражданнар оборонасы хезмәткәрләренең һәм вазыйфаи затларыныц квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

– гражданнар оборонасы өлкәсендә белемнәрне пропагандалау.

15.2. Халыкка хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар аркасында килеп чыккан куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта хәбәр итү буенча түбәндәгеләр:

– халыкка үзәклаштерелгән хәбәр итү системасының даими әзерлеге торышында тоту, аны реконструкцияләү һәм модернизацияләү;

– халык күпләп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат җиткерүнең махсус техник чараларын урнаштыру;

– мәгълүмат җиткерү очен муниципаль берәмлекнец бердәм электр элемтәсе челтәрен, радио -, чыбыклы һәм телевизион тапшырулар челтәрләрен һәм башка техник чараларны комплексль файдалану;

– гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу.

15.3. Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү буенча түбәндәгеләр:

– халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч янау зоналарыннан куркынычсыз районнарга эвакуацияләү буенча чараларны планлаштыру, әзерләү һәм үткәрүне оештыру, шулай ук үз эшчәнлеген сугыш вакытында дәвам итүче оешма хезмәткәрләрен һәм куркынычлык зоналарында гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешма хезмәткәрләрен аеру ;

– эвакуацияләнергә тиешле халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне урнаштыру өчен куркынычсыз районнар әзерләү;

– эвакуация органнары эшчәнлеген булдыру һәм оештыру, шулай ук аларның шәхси составын әзерләү.

15.4. Халыкка шәхси һәм күмәк саклау чаралары бирү буенча түбәндәгеләр:

– гражданнар оборонасыныц саклагыч корылмаларын һәм аларның техник системаларын билгеләнеше буенча файдалануга һәм техник хезмәт күрсәтү буенча даими әзерлек хәлендә тоту, саклау;

– билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы төркемнәренә кертелгән территорияләрне инженерлык ягыннан саклауны арттыру планнарын эшләү;

– тыныч вакытта һәм гражданнар оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә, тирәнрәк биналар һәм җир асты киңлекләрендәге башка корылмаларны халыкны яшерү өчен яраклы итү.;

– сугыш вакытында гражданнар оборонасыныц җитмәгән саклагыч корылмаларын төзүне планлаштыру һәм оештыру;

– гражданнар оборонасының саклау корылмаларында, тирән биналарда

һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларында халыкны яшерүне тәэмин итү;

– халыкны шәхси саклану чараларын туплау, саклау, яңарту һәм билгеләнеше буенча куллану ;

– халыкка шәхси саклану чараларын һәм күмәк саклану чараларын билгеләнгән срокта бирүне тәэмин итү.

15.5. Яктылык һәм башка төр маскировка буенча түбәндәгеләр:

– маскировкаланырга тиешле объектлар исемлеген билгеләү;

– билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы буенча төркемнәргә кертелгән территорияләрне комплекслы маскировкалауны гамәлгә ашыру планнарын эшләү;

– яктырткыч һәм башка төр маскировка чаралары үткәрү өчен кирәкле матди-техник чаралар запасларын булдыру һәм аларны билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту ;

– билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы төркемнәренә кертелгән территорияләрнең маскировкалауга комачаулык итүче билгеләрен киметү буенча инженер-техник чаралар үткәрү.

15.6. Хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә халык өчен куркыныч барлыкка килгән очракта авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару буенча түбәндәгеләр:

– авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен кирәкле гражданнар оборонасы көчләре һәм чараларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасын булдыру, җиһазлау һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;

– авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне һәрьяклап тәэмин итү өчен матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм аларны билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту .

15.7. Хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән халыкның беренче чиратта тормышын тәэмин итү буенча түбәндәгеләр:

– халыкның беренчел яшәешен тәэмин итүнең төп төрләрен планлаштыру һәм оештыру;

– матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту (элек кабул ителгән карарлар нигезендә район икътисады объектлары) ;

– халыкны азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән кирәкле дәрәҗәдә тәэмин итү;

– халыкка коммуналь-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү;

– зыян күргән халык арасында санитар-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

– дәвалау-эвакуация чараларын үткәрү;

– куркынычсыз районда кирәкле дәвалау базасын җәелдерү, аны энергия һәм су белән тәэмин итүне оештыру;

– халыкка беренче ярдәм күрсәтү;

– тораксыз калган халык санын билгеләү;

– сакланган торакны инвентаризацияләү һәм зыян күргән торак фондының торышын бәяләү, зыян күргән халыкны урнаштыру өчен аны куллану мөмкинлеген билгеләү;

– зыян күргән халыкны ял йортларында, пансионатларда һәм башка сәламәтләндерү учреждениеләрендә, вакытлыча торакларда (җыелма йортларда, палаткаларда, землянкаларда һ. б.) урнаштыру, шулай ук аны сакланып калган торак фонды мәйданына күчерү;

– халыкка мәгълүмати-психологик ярдәм күрсәтү.

15.8. Хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән янгыннарга каршы көрәш буенча түбәндәгеләр:

– авария - коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару районнарында һәм билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категориясенә кертелгән оешмаларда сугыш вакытында янгыннарны сүндерүне оештыру;

– янгыннарны сүндерү өчен химик реагентлар запасларын алдан булдыру.

15.9. Радиоактив, химик, биологик һәм башка зарарлануларга (пычрануга) дучар булган районнарны ачыклау һәм билгеләү буенча:

– радиоактив пычрануга дучар булган территорияләрдә радиацион яклау режимнарын кертү;

– радиацион, химик, биологик хәл торышын мониторинглауныц методларын һәм техник чараларын камилләштерү, шул исәптән азык-төлек һәм әйләнә-тирә мохит объектларының радиоактив, химик һәм биологик матдәләр белән зарарлану дәрәҗәсен бәяләү.

15.10. Халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү буенча түбәндәгеләр:

– дезактивлаштыручы, газлаучы һәм дезинфекцияләүче матдәләр һәм эремәләр запасларын алдан булдыру;

– халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү өчен көч булдыру һәм җиһазлау, аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

– халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү чараларын үткәрүне оештыру.

15.11. Хәрби конфликтларда яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык акцияләре нәтиҗәсендә зыян күргән районнарда тәртипне торгызу һәм саклау буенча түбәндәгеләр:

– җәмәгать тәртибен саклау көчләрен булдыру һәм җиһазлау, аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

– җәмәгать тәртибен торгызу һәм саклау, гражданнар оборонасы көчләренең хәрәкәт итү һәм халыкны эвакуацияләү маршрутларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

– авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен гражданнар оборонасы көчләренең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү;

– җыелу учакларында пропуск режимын гамәлгә ашыру һәм җәмәгать тәртибен саклау;

– эчке эшләр органнары тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны саклауны, юридик һәм физик затларның килешүләр буенча мөлкәтен саклауны көчәйтү, караучысыз калган мөлкәтне саклау буенча чаралар күрү.

15.12. Хәрби вакытта кирәкле коммуналь хезмәтләрнең тиз арада эшләвен торгызу мәсьәләләре буенча түбәндәгеләр:

– коммуналь хезмәтләрнең хәрби вакыт шартларында эшләргә әзерлеген тәэмин итү, аларның эш-гамәлләрен планлаштыру;

– зыян күргән газ, энергия, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу һәм канализация системаларын ремонтлау өчен җиһазлар һәм запас частьләр запасларын булдыру ;

– су чистарту, төчеләндерү һәм транспортлау өчен мобиль чаралар резервын булдыру һәм әзерләү;

– суүткәргеч станцияләрендә реагентлар, реактивлар, консервантлар һәм дезинфекция чаралары запаслары булдыру;

– халыкны коммуналь тәэмин итүне оештыру өчен резервуарлар һәм сыешлыклар, җыела һәм сүтелә торган торба үткәргечләре, мобиль резерв һәм автоном энергия чыганаклары, җайланмалар һәм техник чаралар запасларын булдыру.

15.13. Сугыш вакытында мәетләрне тиз арада күмү буенча түбәндәгеләр:

– алдан, тыныч вакытта, мөмкин булган күмелү урыннарын билгеләү;

– мәетләрне күмү чараларын тәэмин итү өчен, шул исәптән махсуслаштырылган ритуаль оешмалар базасында, гражданнар оборонасы көчләре һәм чараларын булдыру, әзерләү һәм әзерләүне тәэмин итү;

– һәлак булган кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) җирләү (күмү) урыннарын җиһазлау;

– мәетләрне эзләү, аларны тапкан урыннарны билгеләү, аларны алу һәм беренчел эшкәртү, үлүчеләрне тану һәм документлаштыру, ташу һәм күмү буенча эшләрне оештыру;

– санитар-эпидемиологик күзәтчелекне оештыру.

15.14. Хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын тәэмин итү буенча:

– тыныч һәм хәрби вакытта икътисад объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча комиссияләрне булдыру һәм аларның эшен оештыру ;

– икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук җитештерү чараларын төзелеш нормалары һәм гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләре таләпләренә туры китереп рациональ урнаштыру;

– гражданнар оборонасының тыныч һәм хәрби вакытта инженер - техник чараларын, шул исәптән төзелеш проектларын эшләү һәм тормышка ашыру;

– сугыш вакытында эшне дәвам итүче икътисад объектларында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү;

– җитештерү процессын торгызу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын алдан булдыру;

– документларның иминият фондын булдыру;

– заманча җиңелү чаралары тәэсирендә җитештерү фондларын яклауның нәтиҗәлелеген арттыру.

15.15. Гражданнар оборонасы көчләренең һәм чараларының даими әзерлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча түбәндәгеләр (Саба районы коткару хезмәтләре (Гражданнар оборонасы хезмәтләре) башлыкларына йөкләнгән):

– гражданнар оборонасы көчләрен заманча техника һәм җиһазлар белән тәэмин итү һәм булдыру;

– гражданнар оборонасы көчләрен гамәлләргә әзерләү, гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм күнекмәләр үткәрү;

– гражданнар оборонасы көчләренең гамәлләрен планлаштыру;

– гражданнар оборонасы көчләре һәм чараларын җәлеп итүнең һәм аларның үзара хезмәттәшлегенең тәртибен билгеләү, шулай ук аларның гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү.

16. Саба муниципаль районының гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау чараларын финанслау Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.